# КИТКӘННӘРНЕҢ ЮЛЫ УРАУ...

«Киткәннәрнең юлы урау...» Шагыйрь Мөхәммәт Шәйхинең каләмдәше Фәннур Сафинга багышлап язган шигырен укыгач, күңелгә шундый юллар уелып калды. Әйе, замана кырыс, хәтер сыек. Бик яшьли дөньядан киткән шагыйрьләрнең генә түгел, әдәбиятта ат уйнаткан, исән чагында телдән төшмәгән каләм ияләренең дә исеме, иҗаты, әгәр аларны кайгыртучы булмаса, вакыт тузаны астында тиз җуела.

Шагыйрьдән чамалап була —
Халыкның нинди көче.
Шагыйрьләр күктән иңә дә
Яшиләр халык өчен...

Бусы да Мөхәммәт Шәйхи шигыреннән. Тик инде икенче бер шагыйрь — нечкә лирик Мизхәт Хәбибуллин вафатыннан соң язылган.

Миңа соңгы елларда Кадыйр Сибгатуллин, Хәниф Хөснуллин, Зариф Мөэминовның әдәби мирасы белән шөгыльләнергә туры килде. Мәсәлән, Зариф Мөэминов исеме әдәбият сөючеләргә бөтенләй таныш түгел дип беләм. Ачыш дисәң дә ачыш! Ярты гасырдан артык ничә повесте, хикәяләре дөньяга чыгуны өмет итеп чормада яткан бит! Күптән түгел «Безнең мирас» журналында әлеге фольклорчы-язучының «Мәрьям» повесте басылып чыкты. Әдәби мирасны өйрәнү — шактый четерекле эш. Әдәбиятыбыз милли рухыбызны сугарып торган әбелхәят суы бит ул. Анда бер генә исем дә онытылырга тиеш түгел. Әдәби чорлар рухын, аларның мәдәни сурәтен тулы килеш күзаллау өчен әдәбиятыбызда ныклы урын алган әдипләрнең әсәрләрен өйрәнү генә җитми.

Моның өчен әдәби хәрәкәткә катнашы булган барлык шәхесләрнең мирасын тикшерү таләп итеlә. Бер чор әдипләре иҗатындагы аваздашлыкны, эстетик, рухи эзләнүләрнең үзенчәлекләрен күзәтү кызыклы һәм әһәмиятле нәтиҗәләргә китерә.

Мөхәммәт Шәйхи шигърияттә үз тавышын узган гасырның 70 нче еллар уртасында ишеттерә. Нык итеп, күпләрне сискәндерерлек итеп... Көндәлек матбугатта шигырьләре күренеп торса да, «Көн үзәге» дигән беренче шигырь китабы 1984 елда гына дөнья күрә. Тагын ике елдан балалар өчен «Уткүз» исемле җыентыгы басылып чыга. Беренче шигырьләре белән үк милләткә хезмәт итәргә алынган каләм әһеле икәнен раслый ул. Борынгыдан килгән җыр-моңнар, халкыбызның үткәне, тарихта тоткан урыны белән ныклап кызыксынуы һәр шигырендә диярлек чагылыш таба. Әмма аларның күпчелеге, дөнья күрмичә, шагыйрьнең архивында гына сакланган. Урау юллар үтеп, әлеге архив Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев кулына килеп керә, ул исә, бу мирасны барлап, аерым китап итеп төзү эшен миңа тәгаенләде.

Мөхәммәт Шәйхи (Мөхәммәтвәли Шәйхетдин улы Шәйхетдинов) 1949 елның 25 сентябрендә Татарстанның Мамадыш районы, Еники-Чишмә (Түбән Кыерлы) авылында дөньяга килә. Хезмәт юлын колхозда башлап җибәрә. 1971 елда (кайбер мәгълүматлар буенча 1974 елда) Түбән Кама шәһәренә килеп урнаша һәм төзелештә электр белән эретеп ябыштыручы (шагыйрь Мизхәт Хәбибуллин кебек үк) булып эшли башлый. Тиз арада шәһәрнең «Кама таңнары» әдәби берләшмәсендә үз кешегә әйләнә, талантлы шагыйрь, рәссам буларак ихтирам яулый. Беренче мәртәбә мине аның белән шагыйрь күңелле мәгърифәтче-педагог, Чаллы шәһәрендәге 2 нче гимназия директоры Рифкать Муллин таныштырган иде. Дөньялар кайный башлаган 90 нчы еллар башы иде ул. Рифкать әфәнде гимназия диварларын, милли тарихыбыз сәхифәләренә нигезләнеп, бизәү эшенә керешкән иде.

Мөхәммәт шушы эшкә катнашып киткән икән. Ул чагында Рифкать Муллин миңа: «Мөхәммәт Шәйхи — баштанаяк милли гамь белән янучы шагыйрь. Хәзерге вакытта «милләт» дип кычкыручылар күп, ә Мөхәммәт Шәйхи 70 нче еллар башында ук халкыбыз язмышы, милләт тарихына багышланган гүзәл шигырьләр язды. Шуңа күрә аны, китаплары чыгуга да карамастан, Язучылар берлегенә дә алмый йөрттеләр», — дип, шагыйрь язмышына беркадәр ачыклык та керткән иде. Мөхәммәт Шәйхи ул чакта хәтта «Асылтауда асылкошлар яши» дип исемләнгән тарихи әсәр дә яза башлаган булган. Архивында сакланган кулъязмада әсәрнең 30лап бите бар. Әсәр 1236 елгы вакыйгалардан, ягъни Болгар дәүләтенә монгол явы һөҗүм иткән чордан, 13 яшьлек үсмер малай сөйләве рәвешендә башланып китә. Кереш өлештәге бер өзектән дә шагыйрьнең язарга ниятләгән әсәренең рухын чамаларга була: «Һәр кеше үзенең җиде бабасын белергә тиеш. Җиде бабасын белмәгән ул әле кеше түгел. Дөньядан үзенең кем икәнен белмичә китүчеләр дә аз түгел. Әлбәттә, моңа ул гына гаепле түгелдер, димәк, аңа этисе исән чагында әйтеп калдырмаган. Акыл кергәч, җиде бабасын эзләгәннәр һәм тапканнар да шактый. Кеше үз-үзен хөрмәт итсә, үз бәһасен тойса, үткәне турында уйлый, кызыксына башлый. Бу гомер-гомердән шулай. Эзләнүнең чиге юк. Ә мәнсезлекнең чикләре тагын да киңрәк...

Мин үземне эзлим...
Урманнарга керәм — мин андадыр.
Тауларга менәм — мин андадыр.
Далаларга чыгам — мин андадыр.
Диңгез буена киләм — мин андадыр...

Кычкырам. Миңа каршы «мин» җавап бирә: «Мин монда!»

Болгар, Суар, Биләр, Җүкәтау шикелле бөек шәһәрләр гөрләп яшәгән төбәкләргә киләм. Аннан да миңа дәшәләр: «Мин монда! Мин монда!! Мин монда!!! Монда!.. Монда!.. Монда!!!»

Үткән белән бүген арасында, бүген белән киләчәк арасында бәргәләнә-бәргәләнә Хәтер очып йөри... Хәтер — мин! Мин — хәтер!..»

Кызганыч, әсәр фәлсәфи-хисси дулкында шактый өметле башланса да, дәвам ителмичә, шулай ниеттә генә калган булса кирәк...

Мөхәммәт Шәйхи уртачадан озынрак гәүдәле, чандыр кыяфәтле булып истә калган. Бирчәеп беткән уч төпләре кытыршы, куллары авыр, хәрәкәте салмак, ара-тирә сүз кыстырып куя да башын арткарак ташлап тын кала. Рәссамнарда була торган поза шулдыр инде, дип уйладым ул чакта. «Аргамак» журналында проза, шигърият һәм әдәби тәнкыйть бүлеген алып баручы буларак, мин Мөхәммәт Шәйхинең шигырьләрен журналга да әзерләп биргән идем. Бер шигыре соңрак, 1992 елда, журналда басылып чыкты. Очрашкан чакларда сөйләшкәләп йөрсәк тә, нигәдер «Аргамак» белән арасы бик якынаеп китә алмады аның.

Разил Вәлиев Чаллы язучылар оешмасын җитәкләгәндә, Мөхәммәт Шәйхи берара шунда, пропаганда бүлегендә дә эшләп алган. Әмма ул бу форсаттан да файдаланмаган, Язучылар берлегенә керү һаман кичерелә килгән. Ә Түбән Камада әдәби мохит иҗат кешеләре өчен бик үк җиңелдән булмагандыр, күрәсең. Мизхәт Хәбибуллин да күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинга юллаган хатында: «Түбән Каманың әдәби торышында атмосфера начар», — дип язган. Шуны истә тотыптыр инде, Кадыйр Сибгатуллин талантлы иҗатны вакытында күреп, дөрес бәяләү җитенкерәмәгәндә, әдәбиятка зур зыян ясалуы хакында ачынулы сүзләр язып калдыра. Чаллыга килү белән, ул Мөхәммәт Шәйхинең шигырьләре белән таныша, шигъриятен зурлап сүз әйтә һәм аңа берлеккә керү өчен тәкъдимнамә яза.

Мөхәммәт Шәйхи — традицион өслүбтә иҗат итүче лирик-фәлсәфи шагыйрь. Шигъри тыны иркен, шигырьгә салынган образларга хилафлык китерми, тема белән

җитди эш итә, шигырьнең «төшен» чыгарып бетерергә омтыла. Хәсән Туфан, аның иҗаты белән ныклап танышса, ихтимал, М. Шәйхине дә «гүзәл гамь»ле шагыйрьләр рәтендә атар иде…

Мөхәммәт Шәйхи 1996 елның 15 февралендә дөнья куя. Аның вафатының сәбәбе бүгенгәчә төгәл ачыкланмаган. Шагыйрьнең җәсәден бер йортның подъездыннан табып алалар. Аннан алда гына ул рәссам дусты В. Мәхмүтов белән сөйләшеп, гармун уйнап, моңга тулышып утырган була. Бу хәбәрне ишеткәч, Василий Мәхмүтов, ярсуына чыдый алмыйча, гармунны 9 нчы каттан аска томыра… Ә аннан да алдарак, вафатына бер атна кала, Мөхәммәт Шәйхи беркайда дөнья күрмәгән шигырьләрен Түбән Камада чыгып килгән «Туган як» газетасына кертеп бирә. Әлеге шигырьләр газетада берничә ел дәвамында басыла тора, аннан инде алар 2001 елда Разил Вәлиев тырышлыгы һәм Таһир Нәбиуллин ярдәме белән «Милли китап» нәшриятында дөнья күргән «Ак буран» исемле җыентыкта урын ала. «Ак буран» җыентыгы басылып чыккач, Рифкать Муллинның «Шигырьләре үксез булмасын» (Туган як. — 2002, 5 февраль), Айдар Хәлимнең «Шигъриятебезнең Мокамаемы… әллә яңа Акмулласымы» (Шәһри Казан. — 2005, 8, 15, 16 июль саннары) мәкаләләре дөнья күрә. Инде менә сезнең кулда шагыйрьнең яңа җыентыгы. Билгеле, бу китапка Мөхәммәт Шәйхинең барлык шигырьләре дә кергәндер дип әйтеп булмый. Шагыйрь иҗатын барлауны дәвам итәргә кирәк.

Киткәч, кайтуы кыен шул,
Кайтуы кыен киткәч…
Бәлки, инде мәңгелеккә
Кайтыр вакытлар җиткән…

Мөхәммәт Шәйхинең иҗаты татар шигъриятендә лаеклы урын алыр дип ышанам. Аның, урау юллар узып, кайтыр чагы җитте. Мәңгелеккә!

**Факил Сафин,**
*филология фәннәре кандидаты*